**Республика Татарстан**
**Совет Большенуркеевского сельского поселения Сармановского муниципального района**

Ул. Школьная, д. 32, с. Большое Нуркеево
Сармановский район, 423372

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлеге Советы**

Мәктәп урамы, 32 нче йорт, Зур Нөркәй авылы, Сарман районы, 423372

---

РЕШЕНИЕ
21 сентябрь 2020 ел

КАРАР
№ 7

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата түләү күләмен арттыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» 2020 елның 06 августындагы 658 номерлы карары, «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Сарман муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Ул Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең сайланулы вазыйфаи затына хезмәт өчен түләү нигезләмәсен раслау турында» 2018 елның 23 апрелендәге 57 номерлы карары белән расланган Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата түләү күләмен 2020 елның 1 октябреннән 1,03 тапкырга арттырырга.

2.Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Интернет челтәрендә Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Зур Нөркәй авыл җирлеге
Советы Рәисе — Р.М.Гайсин